КАРАР

2020 елның 1 декабре № 1

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Беренче Май авылында узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 29 ноябрендә үткән гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Беренче Май поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Беренче Май поселогында 1 Май урамына вак таш җәю ; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

« РИЗА» "КАРШЫ"

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 19 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 10 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» дип гражданнар җыенында катнашучы 10 кеше тавыш бирде;
«юк» дип гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.
Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Беренче Май авылында узган гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре – кабул ителгән дип танырга.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Беренче Май поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Беренче Май поселогында 1 Май урамына вак таш җәю ; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

« РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ятмас Дусай Авылы Башлыгы
авыл җирлеге башлыгы Ф. Х. Гарифуллина